**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 гыйнвар № 32

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 октябрь, 507 нче; 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктның 3.3.3 нче пунктчасындагы егерме сигезенче абзацка «, шул исәптән Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техника кертү тибындагы махсус икътисадый зона объектларын төзү һәм аларның эшләве, резидентлар җәлеп итү эшләрен яраштыруны гамәлгә ашыра.» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков